ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» декабря 2025 г. № 364

Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2022елның16 декабрендә кабул ителгән 326 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең «Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендә кабул ителгән 273-ФЗ нче номерлы Федераль законына, Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендә кабул ителгән 647 нче номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»гы Указына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2022елның 16 декабрендә кабул ителгән 326 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында»гы карарының 1 нче пунктында:

1.1 подпунктны түбәндәге редакциядә язарга:

«1.1. Махсус хәрби операциядә катнашучы, махсус хәрби операциядә катнашкан һәм «Сугышчан хәрәкәтләр ветераны» статусына ия булган гражданнарның гаиләләреннән, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләреннән булган, Әгерҗе муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмаларында укучылар һәм тәрбияләнүчеләр өчен:

1) Әгерҗе муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны (5-11нче сыйныфлар) бушлай ике тапкыр туклandырырга, моның чыгымнарын Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы бюджеты каплаячак;

2) Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында тәрбияләнүче балалар өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү.

1.2 подпункт түбәндәге редакциядә язарга:

1.2. Хәрби хәрәкәтләрдә катнашучы, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан һәм "Сугышчан хәрәкәтләр ветераны" статусына ия булган гражданнарның гаиләләреннән, шулай ук хәрби хәрәкәтләрдә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләреннән булган балалар өчен:

- Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына чираттан тыш кабул итү хокукын бирү.

2. Әлеге карарның гамәле 2025 елның 1 сентябреннән килеп туган мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**